ГЛАВА ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Куркачи , ул. Клубная , 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур.,4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:.Ikaz.Vsg@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«22» октября 2025г. №7

Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Урматы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

"Хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге Уставының 22 нче карары һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 21 октябрендәге 167 номерлы карары ( 19.05.2020 ел, 187 номерлы редакциядә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске Казан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар кылды:

1. Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Татар Урматы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 14 ноябрендә 15 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Биектау Иске Казан авыл җирлегенең Татар Урматы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту .

"КАРШЫ" ӨЧЕН.

3. 2026 елда свода катнашучыларны, аларның гаилә әгъзаларын, 1 төркем инвалидларны һәм 90 яшьтән артык гражданнарны үзара салым түләүдән азат итәргә .

4. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

5.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Глава Иске-Казанского
сельского поселения Г.Р.Закирова